**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**13.12.2021ел** **№ 52**

**Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлеше, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 18 ноябрендәге 197 нче Карары белән расланган "Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән Вәкаләтләрнең бер өлешен бирү (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибе", «Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча төзекләндерү өлкәсендәге вәкаләтләрнең бер өлешен тапшырырга:

тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерү буенча;

җир эшләрен эшләүгә рөхсәтләр бирү;

төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль.

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы Советына карау өчен җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында килешү төзү буенча Биектау муниципаль районы Советы карарын алган вакыттан 10 көннән артмаган срокта эш башкарырга.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина